Р Е С П У Б Л И К А  Т А Т А Р С Т А Н
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Тенишевского**
**городского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

Т А Т А Р С Т А Н  Р Е С П У Б Л И К А С Ы
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Тенеш**
**штп. җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул.Ленина, 8,пгт. Тенишево, 422839
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

Ленина урамы, 8,Тенеш штп, 422839,
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 гыйнвары №1

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә 2021 елга җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6424 сум 98 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т. п., Ленин ур., 8 йорт;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш. т. п., Пионер ур., 18 йорт,

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Е. Изотова

Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш
шәһәр тибындагы поселогы башкарма
комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3850,02 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка озату | 547,86 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |

Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

2021 елның 1 февраленнән «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сум) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 197,58 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3652,44 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 547,86 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2027,10 |
| Барлыгы | 6424,98 |